Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Урманай авылы № 17/38 “ 03 ” октябрь 2016 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
Урманай авыл җирлеге территориясендә җирле
референдум билгеләү турында

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Урманай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Урманакй авылы башкарма комитетының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 15 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Урманай авыл җирлеге Советының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 16/37 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Урманай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Урманай авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 20 ноябрь 2016 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:

“Сез, Урманай авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2017 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1) Зиратларны төзекләндерү һәм тәртиптә тоту 89 мең сум узарасалым акчасын тоту, шуның эченнән:

-Урманай авылы зиратының коймаларын алыштыруга -89 мең сум;

2) Урманай авыл җирлеге биләмәсендә тозекләндерүне оештыруга 36 мең сум узарасалым акчасын тоту, шуның эченнән:

- Беренче Май бистәсе Боек Ватан сугышы һәйкәлен тозекләндерүгә -36 мең сум;

“РИЗА” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга:

http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис: А.И.Закиров